ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 145-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов тарафыннан кертелгән «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 145-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 505-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев, Н.Н. Хаҗипов
тарафыннан кертелә

**«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктта «хуҗасыз» сүзен «Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү эшчәнлегеннән тыш, хуҗасыз» сүзләренә алмаштырырга;

2) кушымтада:

а) 6 пунктның 6 пунктчасында «дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

б) 9 пунктта «дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия

Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) 11 пунктның тугызынчы абзацында «дәвалап булмаслык авыр чирләре яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

г) 16 пунктның бишенче абзацында «дәвалап булмаслык авыр чиренә яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләренә бәйле рәвештә» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга;

д) 20 пунктның беренче абзацында «дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булган» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 86 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ пунктлар өстәргә:

«$6^1$) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә барлыкка килгән вазгыятьне хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятькә кертеп карау критерийларын билгеләү;

$6^2$) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү тәртибен һәм аны хәл итү өчен гамәлгә ашыру мөмкин булган чаралар исемлеген раслау;

$6^3$) хайваннарны вакытлыча тоту пунктлары эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау;»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $1^2$ пункт өстәргә:

«$1^2$) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турында карар кабул итү һәм Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүне тәэмин итү;»;

2) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ статья өстәргә:

«$5^1$ статья. **Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар исемлеге**

Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга түбәндәге чаралар кирә:

1) хуҗасыз хайваннарны аулау, шул исәптән аларны транспортировкалау һәм кичектергесез рәвештә хайваннар приютларына тапшыру;

2) хуҗасыз хайваннарны хайваннар приютларында Федераль законның 16 статьясындагы 7 өлеше нигезендә тоту;

3) югалган хайваннарны аларның хуҗаларына кире кайтару, шулай ук хайваннар приютларына китерелгән хуҗасыз хайваннарга яңа хуҗалар эзләү;

4) сәбәпсез агрессивлык күрсәтми торган хуҗасыз хайваннарны Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны үткәргәннән соң элек яшәгән җирләренә кире кайтару йә Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә хайваннарга карата мөнәсәбәт;

5) элек яшәгән җирләренә кире кайтарыла алмый торган хуҗасыз хайваннарны аларны яңа хуҗаларга тапшырганчы яисә алар табигый рәвештә үлгәнче хайваннар приютларына урнаштыру һәм аларда тоту;

6) хайваннарны вакытлыча тоту пунктларында хуҗасыз хайваннарны тоту;

7) әлеге Законның $5^2$ статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән очракларда хуҗасыз хайваннарны юк итү;

8) Федераль законның 18 статьясындагы 7 һәм 8 өлешләре нигезендә башка кирәкле чаралар.»;

3) түбәндәге эчтәлекле $5^2$ статья өстәргә:

«$5^2$ статья. **Хуҗасыз хайваннарны юк итү чараларын гамәлгә ашыру**

1. Хайваннар приютларындагы хайваннарны, хайванның ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булганда яшәүгә сәләтсез хайваннарның төзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булган очраклардан тыш, юк итү тыела.

2. Хайваннарны вакытлыча тоту пунктларындагы хуҗасыз хайваннарны юк итү тыела, моңа түбәндәге очраклар керми:

1) хайванның ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булганда яшәүгә сәләтсез хайваннарның түзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булганда;

2) ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан хайванның кеше һәм (яисә) башка хайваннар өчен куркыныч булган авыруы булуы факты ачыкланганда йә хайван бу авыруны таратучы булганда;

3) хуҗасыз хайванда сәбәпсез агрессия булганда;

4) Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны үткәргәндә;

5) хуҗасыз хайван кешегә һөҗүм иткәндә.

3. Хуҗасыз хайваннарны юк итү процедурасы ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан тиз һәм авыртусыз үлемне гарантияли торган гуманлы алымнар белән башкарылырга тиеш.»;

4) түбәндәге эчтәлекле $5^3$ статья өстәргә:

«$5^3$ статья. **Хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимы**

1. Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять барлыкка килгән очракта Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендәге вәкаләтле органы Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турында карар кабул итә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турындагы карарда хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимы кертелә торган территория, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән критерийлар нигезендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү нигезләре, гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеге, шулай ук өч айдан артык булмаган вакытка аны кертү срогы күрсәтелергә тиеш.

3. Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимы кертелгән очракта барлык хуҗасыз хайваннар, шул исәптән алынмый яисә юылмый торган билгеләре булган стерилизацияләнгән хуҗасыз хайваннар да, ауланырга тиеш.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын камилләштерү максатларында Бурятия Республикасы Югары Суды соравына бәйле рәвештә «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге № 498-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 3 өлеше (алга таба – Федераль закон) һәм «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 7 статьясындагы 4 өлешенең, 18 статьясындагы 1 өлешенең беренче абзацының һәм 7 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турында эш буенча» 2024 елның 18 июлендәге 38-П номерлы Россия Федерациясе Конституция Суды карары (алга таба – Суд карары) нигезендә эшләнде.

Закон проекты белән «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (алга таба – 120-ТРЗ номерлы Закон) түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) 4 статьяның 1 өлешенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге вәкаләтләрен өстәргә:

Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә барлыкка килгән вазгыятьне хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятькә кертү критерийларын билгеләү;

Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү тәртибен һәм аны хәл итү өчен гамәлгә ашыру мөмкин булган чаралар исемлеген раслау;

хайваннарны вакытлыча тоту пунктлары эшчәнлеген оештыру тәртибен раслау;

2) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү турында карар кабул итү һәм Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүне тәэмин итү вәкаләтен бирү;

3) Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар исемлеген үз эченә алган $5^1$ статья өстәргә;

4) хуҗасыз хайваннарны юк итү чараларын гамәлгә ашыруны җайга сала торган $5^2$ статья өстәргә. Әлеге статьяда хайваннарны вакытлыча тоту пунктларындагы хуҗасыз хайваннарны түбәндәге очракларда юк итү мөмкинлеге беркетелә:

хайванның ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре булганда яшәүгә сәләтсез хайваннарның түзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булганда;

ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан хайванда кеше һәм (яисә) башка хайваннар өчен куркыныч булган авыруы булуы факты ачыкланганда йә хайван бу авыруны таратучы булганда;

хуҗасыз хайванда сәбәпсез агрессия булганда;

Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятьне хәл итүгә юнәлдерелгән чараларны үткәргәндә;

хуҗасыз хайван кешегә һөҗүм иткәндә;

5) хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимының төп нигезләмәләрен билгели торган $5^3$ статья өстәргә.

Шулай ук закон проекты белән «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган методикага гадәттән тыш вазгыять кертү, хайваннарны вакытлыча тоту пунктлары булдыру һәм хуҗасыз хайваннарны юк итү очракларын киңәйтү мөмкинлеген исәпкә алуга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт эшчәнлеген гамәлгә ашырганда чаралар Федераль законның 18 статьясындагы 1 өлеше белән беркетелгән. Әгәр Россия Федерациясе субъектының закон чыгару акты белән башкасы билгеләнсә, әлеге чаралар үзгәртелергә мөмкин,

Федераль законның 16 статьясындагы 11 өлеше нигезендә хайваннар приютларында тотылган хайваннарны юк итү тыела, хайванның ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан дөрес билгеләнгән дәвалап булмаслык авыр чире яисә хайван гомеренә куркыныч яный торган төзәлмәслек авыр җәрәхәтләре

булганда яшәүгә сәләтсез хайваннарның түзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булган очракларыннан тыш һәм тиешле процедура ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан тиз һәм авыртусыз үлемне гарантияли торган гуманлы алымнар белән башкарылырга тиеш.

Суд карары белән әлеге исемлеккә хуҗасыз хайваннарны юк итү мөмкин булган түбәндәге очраклар өстәлде:

1) хуҗасыз хайван кешегә һөҗүм иткәндә;

2) сәбәпсез агрессивлык күрсәткәндә;

3) куркыныч булган авыруы булганда йә хайван бу авыруны таратучы булганда, шулай ук яшәүгә сәләтсез хайваннарның түзеп булмаслык физик интегүләрен туктату зарур булганда;

4) башка очракларда Россия Федерациясенең субъектында яисә аның территориясенең бер өлешендә гражданнарны хуҗасыз хайваннар һөҗүменнән саклау яисә алар тараткан кеше өчен куркыныч чирләрдән яклау белән бәйле гадәттән тыш вазгыять булганда, һәм хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт эшчәнлеген башкарганда бүтән башка чаралар оештыру объектив рәвештә бу вазгыятьне хәл итүгә китерә алмаган очракта гына мөмкин һәм әлеге чара вакытлы характерда булу шарты белән, шулай ук хайванны аның хуҗасы табу мөмкинлеге өчен тиешле вакыт һәм шартлар карала.

Югарыда күрсәтелгән нигезләр буенча хуҗасыз хайваннарны юк итү Мурманск, Әстерхан, Оренбург, Кемерово, Амур, Магадан өлкәләре, Еврей автономияле өлкәсе, Чуваш, Тыва, Хакасия, Бурят, Саха республикалары, шулай ук Забайкалье һәм Ставрополь крайлары закон актларында каралган.

Закон проектын кабул итү хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гамәлдәге хокукый җайга салуның нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк, бу хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау максатларына ирешүгә ярдәм итәчәк.

**«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы закон актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә барлыкка килгән вазгыятьне хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыятькә кертеп карау критерийларын;

Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять режимын кертү тәртибен һәм аны хәл итү өчен гамәлгә ашыру мөмкин булган чаралар исемлеген;

хайваннарны вакытлыча тоту пунктлары эшчәнлеген оештыру тәртибен.

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан

Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларына үзгәрешләр кертелергә тиеш:

«Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 елның 30 декабрендәге 1275 номерлы;

«Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар приютлары эшчәнлеген оештыру тәртибен һәм аларда хайваннарны тоту нормаларын раслау турында» 2020 елның 28 февралендәге 150 номерлы;

«Татарстан Республикасы территориясендә хуҗасыз хайваннарның гражданнар гомеренә яисә сәламәтлегенә зыян китерүне кисәтү тәртибен раслау турында» 2022 елның 29 декабрендәге 1436 номерлы.

**«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (алга таба – закон) кабул итү «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә, шулай ук хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итми.

Закон проектының «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына Татарстан Республикасы территориясендә яисә Татарстан Республикасы территориясе өлешендә хуҗасыз хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә гадәттән тыш вазгыять (алга таба – гадәттән тыш вазгыять) кертүгә кагылышлы үзгәрешләр өлешендәге нигезләмәләрен кабул итү һәм аларны алга таба гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар бүлеп бирүне таләп итәргә мөмкин.

Гадәттән тыш вазгыять кертүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү күләме һәм чыганаклары, бу вазгыятьнең барлыкка килүнең фаразлана алмый торган характерын исәпкә алып, аны кертү факты буенча билгеләнәчәк.